| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>НУРЛАТСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ГЛАВА АМЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ӘМЗӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Яңа Әмзә ав. **КАРАР**

«17» ноябрь 2025 ел № 9

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Яңа Әмзә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Республикасы Нурлат «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2025 елның 28 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Яңа Әмзә авылы, Ленин урамы, 12нче йорт адресы буенча урнашкан Яңа Әмзә авылы мәдәният йорты бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әмзә авылында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.
2. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез 2026 елда Әмзә авыл җирлегенең Яңа Әмзә авылы территориясендә яшәүче 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар тыш һәр балигъ булган кешедән, 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү ризамы?

1) Яңа Әмзә торак пункты территориясен төзекләндерү;
2) Яңа Әмзә торак пунктындагы чишмә территориясен төзекләндерү;
2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

3) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләре һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Әмзә авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

5 Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әмзә авыл җирлеге башлыгы Ә.Ф.Сафиуллина